ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 85 от «31» 01 2017 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы җирлекара күмү урыннарында
җирләү буенча гарантияле исемлек
нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, “Күмү һәм җирләү эше турында” 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында “Күмү һәм җирләү эше турында” Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” 2007 ел, 18 май, 196 нчы карары, Россия Федерациясе Дәүләт Хакимиятенең “2017 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында" 2017 елның 26 гыйнварындагы 88 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. 2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 31 гыйнварына кадәр күмү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын 5277,28 сумга билгеләргә.

2. Мамадыш муниципаль районында күмү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 5562,25 сум күләмендә билгеләргә һәм 2017 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

3. 2017 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2015 елның 29 декабрендәге “2016 елга Мамадыш муниципаль районында күмү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе турында” гы 1109 номерлы карарын үз көчен югалтты дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.М.Дәрҗемановка йөкләргә.

Җитәкче И.Э.Фәттахов

Мамадыш муниципаль  районы
Башкарма комитетының
31.01 .2017 ел,  №  85 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы җирлекара күмү урыннарында тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булган очракта җирләү  буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| 2.Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2558,65 |
| 3.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 666,70 |
| 4.Кабер казу һәм җирләү | 2336,90 |
| **барлыгы** | **5562,25** |

Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
31.01 .2017 ел, № 85 карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Мәетне киендерү | 793,80 |
| 3.Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 1837,50 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 680,20 |
| 5.Кабер казу һәм җирләү | 2250,75 |
| **барлыгы** | **5562,25** |